Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Оштырма Юмья авыл җирлеге Советы

# КАРАР

«26» март, 2024 ел №10

**Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья авылында «Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 2 номерлы Иске Юмья авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Оштырма Юмья авыл җирлеге Уставы нигезендә, Оштырма Юмья авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 06 апреленә 18 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 2 номерлы Иске Юмья авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Иске Юмья авылы, Үзәк урам, 87 а йорты адресындагы Иске Юмья авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.
2. 2024 елның 06 апреленә 19 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 2 номерлы Иске Юмья авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Иске Юмья авылы, Үзәк урам, 87 а йорты адресындагы Иске Юмья авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 24 ноябрендәге 2 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Оштырма-Юмья авыл җирлеге Иске Юмья авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге

уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Иске Юмья авылының Яр буе урамы, Гвардия урамы, Үзәк урам, Мәктәп урамында юлларны ясау, ремонтлау, карап тоту, вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, салу, сууткәргеч торбалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү, Иске Юмья авылында янгын гидрантларын, янгын сүндерү рукавлары, стволлары, күчергечләре, колонкалары, мотопомпалары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Иске Юмья авылы җир асты суларының (чишмәләрнең) табигый чыгу урыннарын ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү;

- Иске Юмья авылында сууткәргеч системасын, су суырту манарасын, скважиналарны һәм башка инженерлык челтәрләрен ремонтлау, карап тоту һәм төзекләндерү, кул белән һәм экскаватор белән туфрак эшкәртү, торба үткәргеч салу, ремонтлау, су суырту манарасы өчен бетон боҗралар, капкачлар һәм люклар, насос сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, экскаватор һәм манипулятор хезмәтләре өчен түләү, эш өчен шартнамә буенча түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Иске Юмья авылында традицион җирләү урыннарын карап тоту, ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү, җирләү йортын төзү, ремонтлау, чүп контейнерлары сатып алу, урнаштыру, моточапкычлар, бензопычкылар, генератор һәм инвентарь (көрәкләр, тырмалар, ломнар, баскычлар) сатып алу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү;

- халыкның күпләп ял итү урыннарын, парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын, авыл мәдәният йортын төзү, ремонтлау, аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү;

- Иске Юмья авылының урам юл челтәрен карап тоту, кышын юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу, төзекләндерү; трактор һәм чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү;

- урам яктыртуны көйләү, урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү;

- Иске Юмья авылында һәйкәлләрне ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү?

2023 елның 24 ноябрендәге 2 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү системаларын, су саклау зоналарын, су суырту манараларын, артезиан скважиналарын һәм башка инженерлык челтәрләрен ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, бетон боҗралар, капкачлар һәм люклар, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, эш өчен шартнамә буенча түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Иске Юмья авылында су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре)

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Иске Юмья авылында җир асты суларының (чишмәләрнең) табигый чыгу урыннарын ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, эш өчен шартнамә буенча түләү, чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Иске Юмья авылында янгын гидрантларын, янгын сүндерү рукавларын, стволларны, күчермәләрне, колонкаларны, мотопомпаларны карап тоту, сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Иске Юмья авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка эш төрләре);

- һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаганнары) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү - һәйкәлләрне карап тоту, төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, Иске Юмья авылында һәйкәлләрне төзү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Юмья авылының урам юл челтәрен карап тоту, кышын юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу, төзекләндерү; трактор һәм чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, Иске Юмья авылы юл челтәрен карап тоту буенча башка эш төрләре); (Иске Юмья авылының Яр буе урамы, Гвардия урамы, Үзәк урам, Мәктәп урамында юлларны ясау, ремонтлау, карап тоту, вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, суүткәргеч торбалар урнаштыру, эш өчен шартнамә буенча түләү, юлларны карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- торак пункт территориясен төзекләндерү - халыкның күпләп ял итү урыннарын, парклар, скверлар, спортһәм уен мәйданчыклары, халыкның башка күпләп ял итү урыннарын, авыл мәдәният йортын карап тоту, төзү, ремонтлау, аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү, Иске Юмья авылы территориясен төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (коймаларны карап тоту, ремонтлау, төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, төзү, ремонтлау, җирләү йорты төзү, чүп контейнерлары һәм инвентарь сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, эш өчен шартнамә буенча түләү, Иске Юмья авылының традицион җирләү урыннары (каберлеге) территориясен төзекләндерү буенча башка эш төрләре).

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Оштырма Юмья авыл җирлеге
башлыгы: С.В.Тимофеев